# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘКРЕ КҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

## КАРАР

№3 18 октябрь 2024ел

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегенең Яңа Александровка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Кәкре Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә карар бирәм::

1. 2024 елның 13 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегенең Яңа Александровка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: ТР, Аксубай муниципаль районы, Яңа Александровка авылы, Энгельс урамы, 10 нчы йорт янында.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегенең Яңа Александровка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, , Украинадагы махсус операциягә хезмәткә мобилизацияләнгән затлар һәм аларның гаилә әгъзалары, Россия Федерациясе Хәрби көчләре хәрбиләреннән тыш, 2024 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүдән гыйбарәт булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан, күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итүгә таләпләр, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- урамнарны яктырту җайланмасы (Яңа Александровка авылында урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү).

Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш түшәлгән юллар төзү (вак таш ташу, салу, вак ташны тигезләү, комнан һәм грунттан нигез салу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү). Яңа Александровка авылында Карл Маркс урамы буенча; урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, Яңа Александровка авылы килешүе буенча эшләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга. http://aksubayevo.tatar.ru һәм рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Кәкре Күл авыл җирлеге башлыгы С.С.Елисеев